Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча 2023 елның 6 декабрендәге гавами тыңлаулары (җәмәгать фикер алышулары)

НӘТИҖӘСЕ

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты турында фикер алышканнан соң, гавами тыңлауларда катнашучылар тәкъдим ителгән проектның "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 елгы 131 ФЗ номерлы Федераль Законын, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, РФ Җир кодексы, РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә әзерләнгәнен билгеләп үттеләр . Башка өстәмәләр һәм үзгәрешләр килмәде.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча чыгышларны тыңлап, гавами тыңлауларда катнашучылар кара кабул иттеләр:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектында тәкъдим ителгән үзгәрешләрне исәпкә алып: 16:23:010102: 372,16: 23:010102:1076 кадастр номерлары белән җир участогының функциональ зонасын "Күпфункциональ иҗтимагый-эшлекле зона" функциональ зонасына үзгәртү кирәк.

2. Каралган мәсьәләне тиешле карар кабул итү өчен,Кукмара муниципаль районы Советының чираттагы утырышы көн тәртибенә чыгарга..

3. Гавами тыңлаулар буенча йомгакны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмора муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

Рәислек итүче Хәбибуллина Р. Г.